| | | |
|---|---|---|
| АЛЕКСЕЕВСКИЙ<br>РАЙОННЫЙ СОВЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>РАЙОН СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

05.11.2020 п.г.т. Алексеевское № 20

**«Аерым эшчәнлек төрләре өчен кертелгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2016 елның 15 ноябрендәге 63 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында**

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешенә һәм икенче өлешенә һәм «Банклар һәм банк эшчәнлеге турында» Федераль законның 26 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2012 елның 29 июнендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 5 маддәсендәге 8 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Алексеевск муниципаль районы Уставы нигезендә

**Алексеевск муниципаль районы Советы карар итте:**

1. «Эшчәнлекнең аерым төрләре өчен өстәлгән керемгә бердәм салым рәвешендә салым салу системасын гамәлгә кертү турында» Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 2016 елның 15 ноябрендәге 63 номерлы карарын 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда https://pravo.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://alekseevskiy.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны финанс-бюджет палатасы рәисенә һәм бюджет, салымнар һәм финанс буенча даими комиссиягә йөкләргә (Сафина Г.Т.).

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы**
**Совет Рәисе** **С.А. Демидов**